| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЕКСЕЕВСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ АЛЕКСЕЕВСК ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2021г. № 5

**Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе төзү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 8, 31 маддәләре һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 маддәсе нигезендә Алексеевск муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 1 нче кушымта нигезендә Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясен төзергә.
2. 2 нче кушымта нигезендә Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясе турында нигезләмәне расларга.
3. Әлеге карарны Алексеевск муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск шәһәр җирлеге**
**башкарма комитеты җитәкчесе** **И.К. Свистунов**

Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 8 апрелендәге
5 номерлы карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясе
Составы

Комиссия рәисе:

Свистунов И.К. - Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе;

комиссия рәисе урынбасары:

Язынин Р.С. - Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы рәисе (килешү буенча);

комиссия сәркатибе:

Увакина В.В. - Алексеевск шәһәр җирлеге башлыгы урынбасары (килешү буенча);

комиссия әгъзалары:

Добрецов О.П. - ТР Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге депутаты (килешү буенча);
Кәлимуллин Т.Р. - Алексеевск муниципаль районы башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы (килешү буенча).

Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
2021 елның 8 апрелендәге
5 номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының
Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш комиссиясе турында
Нигезләмә

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә җирдән файдалану һәм төзелешне җайга салу системасын булдыру, эзлекле камилләштерү һәм нәтиҗәле эшләвен тәэмин итү өчен Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш буенча комиссиясе төзелә (алга таба - Комиссия).

Комиссия Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары нигезендә төзелә.

Комиссия даими эшли һәм әлеге Нигезләмә нигезендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра.

Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнарына, Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

Комиссия үз эшчәнлеген дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр, шулай ук юридик һәм физик затлар белән үзара бәйләнештә алып бара.

## 2. КОМИССИЯ СОСТАВЫ

2.1. Комиссия составы Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана.

2.2. Комиссия рәисе булмау сәбәпле, аның вазыйфаларын комиссия рәисе урынбасары башкара.

## 3. КОМИССИЯ КОМПЕТЕНЦИЯСЕ

3.1.1. Комиссия компетенциясенә керә:

3.1.2. Җирдән файдалануны һәм төзелешне җайга салу системасын эзлекле формалаштыру һәм камилләштерү процессын оештыру, шул исәптән җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрен эшләү, ә алга таба аларны гамәлгә ашыру;

3.1.3. Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен эшләүгә бәйле рәвештә гражданнарның һәм юридик затларның тәкъдимнәрен карау;

3.1.4. Гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру:

- Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында;
- Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлеген яки капиталь төзелеш объектын шартлы-рөхсәт ителгән файдалануга рөхсәт бирү турындагы сораулар буенча;
- Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең иң чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирү турындагы сораулар буенча;
- Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен планлаштыру проектлары буенча;
- Алексеевск муниципаль районы Алексеевск шәһәр җирлеге муниципаль берәмлеге территориясен межалау проектлары буенча;

3.1.5. Гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә бирү, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә тәкъдимнәр әзерләү.

## 4. КОМИССИЯ ЭШЧӘНЛЕГЕ ТӘРТИБЕ

4.1. Комиссия кирәк саен җыела, ләкин аена бер тапкырдан да ким түгел.

4.2. Комиссия утырышы, әгәр анда Комиссия әгъзаларының билгеләнгән санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, хокуклы дип санала.

4.3. Комиссия карары комиссиянең катнашучылардан күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, рәис тавышы хәлиткеч булып тора.

4.4. Комиссия эшчәнлеген техник яктан тәэмин итү Алексеевск муниципаль районының Алексеевск шәһәр җирлеге башкарма комитетына йөкләнә.